ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.10.2022 п.г.т.Алексеевское № 464

**Бюджет даирәсендә эшләүчеләрнең**
**хезмәт хакын түләү буенча Бердәм**
**тариф челтәре таралмый торган**
**аерым оешмалар хезмәткәрләренең**
**вазыйфаи окладларын арттыру турында**

Бюджет даирәсендә эшләүчеләрнең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре таралмый торган аерым оешмалар җитәкчеләренә, белгечләренә һәм хезмәткәрләренә социаль гарантияләр тәэмин итү максатларында, һәм «Бюджет даирәсендә эшләүчеләрнең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалар хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын күтәрү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2022 номерлы карары нигезендә

**карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башлыгының 24.04.2018 № 40«Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре таралмый торган бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» гы карары белән билгеләгәнчә һәм тәртиптә ,бюджет даирәсендә эшләүче , хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре таралмый торган аерым оешмаларның җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи окладлары күләмнәрен 2022 елның 1 октябреннән күтәрергә.

2. Бюджет даирәсендә эшләүчеләрнең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре таралмый торган бюджет даирәсенең аерым оешмалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи окладлары күләмнәрен исәпләп чыгару өчен, әлеге карарның 1 пункты нигезендә муниципаль берәмлекләрдә бюджет өлкәсендә аерым оешманың структур бүлекчәсе җитәкчесенең Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре таралмый торган секретаренең вазыйфаи оклады күләмен 1,04 тапкырга индексилаштырырга, һәм аны 11 958 сум күләмендә билгеләргә.

4. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

5. Бу карар имзаланган көннән үз көченә керә һәм 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

6. Әлеге карарның үтәлешен финанс-бюджет палатасы рәисе О.Н.Леденцовка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **О.А.Гайнуллин**